ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
24.12.2025

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№**3879

Зеленодольск шәһәренең Дача урамындагы 8а күп фатирлы йорты өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 ст. 4 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның «Күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күп фатирлы йортта тиешле сыйфатта булмаган һәм (яисә) билгеләнгән вакыттан артыграк тәнәфесләр белән гомуми мөлкәт белән идарә итү, карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәткән һәм эшләр башкарган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 13 августындагы 491 номерлы карары, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында, шулай ук мондый түләүнең иң чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 213/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск шәһәре территориясендәге күп фатирлы йортлар белән идарә итү субъектларының күп фатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең КФЙда гомуми мөлкәтне карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү хакында карарлар кабул итмәүләре турындагы мөрәҗәгатьләренә, күпфатирлы йорт белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешма мөрәҗәгатенә бәйле, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2026 елның 01 гыйнварыннан социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, милекчеләре Зеленодольск шәһәренең Дача урамындагы 8а күп фатирлы йорты өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йорт һәм күп фатирлы йортлар белән идарә итү ысулын сайламаган милекчеләр өчен торак урынны карап тотуга түләү күләмен аена 29,63 сум/кв.м., шул исәптән торак фонды белән идарә итү- НДСны исәпкә алып, аена 4,79 сум/кв. м. итеп билгеләргә.

1.1. Әлеге түләү күләме муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләренә күп фатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне үз эченә алмый.

2. Муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы урын милекчеләренә торак урынны карап тоткан өчен түләү составына керүче күп фатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күп фатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан билгеләнә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск шәһәре Дача урамындагы 8а күп фатирлы йорт өчен торак урынны карап тотуга түләү күләме турында» 2024 елның 24 декабрендәге 5208 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин